| КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 30 декабрь г.Казань № 1239

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2021 елга кадәр Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау системасын үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 1 июль, 461 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2021 елга кадәр Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау системасын үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 1 июль, 461 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 15 май, 319 нчы; 2014 ел, 10 декабрь, 966 нчы; 2015 ел, 30 октябрь, 821 нче; 2016 ел, 12 апрель, 215 нче; 2016 ел, 22 сентябрь, 674 нче; 2017 ел, 13 гыйнвар, 4 нче; 2017 ел, 13 февраль, 80 нче; 2017 ел, 26 июнь, 429 нчы; 2017 ел, 4 октябрь, 760 нчы; 2018 ел, 30 июль, 612 нче; 2018 ел, 2 август, 625 нче; 2018 ел, 20 декабрь, 1194 нче; 2018 ел, 20 декабрь, 1197 нче; 2019 ел, 6 июнь, 472 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «2021» саннарын «2025» саннарына алыштырырга;

әлеге карар белән расланган «2025 елга кадәр Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау системасын үстерү» дәүләт программасында (алга таба – Программа):

Программа паспортының «Ярдәмче программалар исемлеге» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Ярдәмче программалар исемлеге | «Авыруларны профилактикалау һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру. Беренчел медицина-санитария ярдәме күрсәтүне үстерү» 1 нче ярдәмче программасы («Җәмәгатьчелек сәламәтлеген ныгыту» 1 нче «а» ярдәмче программасы). |

| | |
|---|---|
| | «Махсуслаштырылган медицина ярдәме күрсәтүне (югары технологияле медицина ярдәме күрсәтүне кертеп), ашыгыч медицина ярдәме күрсәтүне, шул исәптән ашыгыч махсуслаштырылган медицина ярдәме күрсәтүне, медицина эвакуациясен камилләштерү» 2 нче ярдәмче программасы («Татарстан Республикасында йөрәк-кан тамырлары авыруларына каршы көрәшү» 2 нче «а» ярдәмче программасы. «Онкологик авыруларга каршы көрәшү» 2 нче «б» ярдәмче программасы. «2019 – 2025 елларга Татарстан Республикасында трансплантологияне үстерү, югары технологияле медицина ярдәме күрсәтүне камилләштерү, дәвалауның яңа нәтиҗәле ысулларын үстерү» 2 нче «в» ярдәмче программасы).<br>«Дәүләт-шәхси партнерлыгын үстерү» 3 нче ярдәмче программасы.<br>«Ана һәм бала сәламәтлеген саклау» («Татарстан Республикасының балалар сәламәтлеген саклау системасын үстерү (балаларга медицина ярдәме күрсәтүнең заманча инфраструктурасын булдыруны кертеп)» төбәк проекты) 4 нче ярдәмче программасы.<br>«Медицина тернәкләндерүен һәм шифаханә-курорт дәвалавын (шул исәптән балаларга) үстерү» 5 нче ярдәмче программасы.<br>«Паллиатив ярдәм күрсәтү, шул исәптән балаларга» («Татарстан Республикасында паллиатив медицина ярдәме күрсәтү системасын үстерү») 6 нчы ярдәмче программасы.<br>«Сәламәтлек саклау системасын кадрлар белән тәэмин итү» 7 нче ярдәмче программасы.<br>«Дарулар белән тәэмин итү системасын, шул исәптән амбулатория шартларында камилләштерү» 8 нче ярдәмче программасы.<br>«Сәламәтлек саклауда мәгълүматлаштыруны үстерү» 9 нчы ярдәмче программасы.<br>«Татарстан Республикасын территориаль планлаштыру системасын камилләштерү» 10 нчы ярдәмче программасы.<br>«2014 – 2016 елларга Татарстан Республикасының сәламәтлек саклау системасын перинаталь үзәкне проектлаштыру, төзү һәм эксплуатацияләүгә кертү өлешендә модернизацияләү» 11 нче ярдәмче программасы.<br>«2025 елга кадәр Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау системасын үстерү» дәүләт программасы кысаларында социаль һәм инженерлык инфраструктурасын үстерү» 12 нче ярдәмче программасы.<br>«2018 – 2025 елларга медицина оешмаларындагы балалар поликлиникаларының һәм балалар поликлиника бүлекләренең матди-техник базасын үстерү» 13 нче ярдәмче программасы; |

«Паллиатив ярдәм күрсәтү, шул исәптән балаларга» («Татарстан Республикасында паллиатив медицина ярдәме күрсәтү системасын үстерү») 6 нчы ярдәмче программасын яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

Программага теркәлгән 1 нче кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

Программага теркәлгән 2 нче кушымтаның «Паллиатив ярдәм күрсәтү, шул исәптән балаларга» 6 нчы ярдәмче программасы» бүлекчәсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| **«Паллиатив ярдәм күрсәтү, шул исәптән балаларга» 6 нчы ярдәмче программасы<br>(«Татарстан Республикасында паллиатив медицина ярдәме күрсәтү системасын үстерү»)** | | | | | | | | | | |
| 6.1. | Зурларга паллиатив ярдәм күрсәтү өчен койкалар белән тәэмин ителеш | койка/100 мең зурлар | 5,6 | 6,6 | 6,6 | 6,6 | 6,6 | 6,8 | 6,9 | 6,9 |
| 6.2. | Балаларга паллиатив ярдәм күрсәтү өчен койкалар белән тәэмин ителеш | койка/100 мең зурлар | 5,1 | 5,8 | 5,8 | 5,8 | 5,8 | 6,5 | 6,5 | 6,5 |
| 6.3. | Паллиатив медицина ярдәменә мохтаҗ булган пациентларның гомуми санында паллиатив медицина ярдәме күрсәтелгән пациентларның өлеше арту, зурлар | процент | 22 | 30 | 35 | 50 | 60 | 80 | 90 | 90 |
| 6.4. | Паллиатив медицина ярдәменә мохтаҗ булган пациентларның гомуми санында паллиатив медицина ярдәме күрсәтелгән пациентларның өлеше арту, балалар | процент | 55 | 60 | 70 | 80 | 90 | 100 | 100 | 100». |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин